

# Мастер класс “Татар теле дәресләрендә синквейн технологиясен куллану”

Тел-белемнең ачкычы,
акылның баскычы. (Халык мәкале)



Укытучы: Заһидуллина Лилия Ринат кызы

2016 ел


# Нәрсә соң ул синквейн?

Синквейн- француз сүзе, «биш илһам», «биш уңыш» дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Билгеле план буенча языла, предметны (төшенчәне) ачыклый.

# Синквейн язу тәртибе

Синквейн 5 юлдан тора





# Синквейн язу тәртибе

| | |
|---|---|
| 1 юл | Теманы ачыклаучы сүз, исем. (Кем? Нәрсә?) |
| 2 юл | Теманы сурәтли торган 2 сыйфат (Нинди?) |
| 3 юл | Темага хас булган 3 фигыль. (Нишли?) |
| 4 юл | Темага карата үз мөнәсәбәтеңне белде-рүче фраза, җөмлә (афоризм, мәкаль, цитата) |
| 5 юл | Темага карата 1 синоним сүз (нәтиҗә, ассоциация). |

# Нәрсә турында синквейн язарга була?

Темасы төрле булырга мөмкин:

1. табигать;
2. әдәби герой, персонаж;
3. әни, әти һәм башка гаилә әгъзалары;
4. күңел халәте;
5. дәрестә өйрәнгән тема;

...



# Укучылар иҗаты



Мәктәп

Якты, зур


Тәрбияли, өйрәтә, укыта

Без мәктәпкә теләп йөрибез

Белем

Гилязов Илнат, 4 сыйныф


# Укучылар иҗаты




Кыш
Салкын, карлы.
Туңдыра, шатландыра, бүләк итә.
Кыш бабай бүләкләр тарата.
Яңа ел.

Талипова Язилә, 3 сыйныф




1.
2.
3.
4.
5.


Туган тел
... И туган тел,
и матур тел...

# Синквейнның нәтиҗәлелеге

Тема буенча лексик материал үзләштерелә, сүзлек байлыгы арта;

- Эчтәлекне кыскача сөйләүгә әзерли;
- Тәнкыйди һәм креатив фикерләүне камил ләштерә;
- Ассоциацияләр ярдәмендә алган белемнәр ныгытыла;
- Катлаулы информация гомумиләштерелә;
- Укучы үзен шагыйрь итеп хис итә;
- Бөтен укучы да яза ала.

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

